КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 24 февраль г.Казань № 131

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләрен һәм тәртибен раслау турында» 2005 ел, 15 апрель, 190 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 2 август, 366 нчы; 2010 ел, 3 февраль, 53 нче; 2011 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 16 сентябрь, 659 нчы; 2014 ел, 19 август, 599 нчы; 2015 ел, 13 апрель, 250 нче, 2015 ел, 12 сентябрь, 669 нчы, 2017 ел, 30 сентябрь, 740 нчы, 2020 ел, 28 гыйнвар, 40 нчы, 2020 ел, 31 гыйнвар, 51 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләренә һәм тәртибенә 3 нче кушымтага, 1 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«торак урынында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санын раслый торган белешмәләр;».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру өчен кирәкле документлар формаларын раслау хакында» 2008 ел, 31 гыйнвар, 57 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 08 октябрь, 914 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган исәп эшнамәсен алып бару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

унберенче абзацта «дәвалау медицина учреждениесе» сүзләрен «медицина

оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

унөченче абзацта «учреждениеләр» сүзләрен «оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

ундүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«е) торак урынында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санын раслый торган белешмәләр;»;

уналтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«з) хокукларны дәүләт кадастр исәбен, хокукларны дәүләт теркәвенә алуны, Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрын алып баруны һәм Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрындагы (алга таба – хокукларны теркәү органы) булган мәгълүматларны тапшыруны, гаилә әгъзаларының даими яшәү урыны буенча милек хокукында торак урыннары булу яки булмау турында гариза биргәнчегә кадәр биш ел эчендә мөрәҗәгать итүче гаиләсенең эшкә сәләтле һәр әгъзасы тарафыннан бирелә торган белешмәләр;»;

унсигезенче абзацта «дәүләт исәбе һәм мөлкәти хокукларны теркәү органнары» сүзләрен «хокукларны теркәү органы» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күп балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында» 2007 ел, 18 декабрь, 732 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 ел, 16 май, 326 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 29 август, 619 нчы; 2009 ел, 15 июнь, 394 нче; 2011 ел, 20 декабрь, 1021 нче; 2013 ел, 11 июнь, 398 нче; 2016 ел, 27 июнь, 443 нче; 2016 ел, 27 июль, 515 нче; 2016 ел, 5 декабрь, 891 нче; 2017 ел, 24 октябрь, 806 нчы, 2019 ел, 09 август, 660 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күп балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренә, 9 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«г) торак урынында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санын раслаучы белешмәләр;».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында һәм гражданнарның кайбер категорияләрен торак урыннар белән тәэмин итү турында» 2010 ел, 8 декабрь, ФЗ-342 нче Федераль закон нигезендә торак урыннар белән тәэмин ителүче гражданнарга милеккә түләүсез яки социаль найм буенча торак урыннар бирү, аларга торак урын сатып алу йә төзү өчен бер тапкыр акчалата түләү бирү кагыйдәләрен раслау хакында» 2011 ел, 9 август, 643 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 22 февраль, 124 нче, 2015 ел, 24 октябрь, 800 нче; 2016 ел, 19 апрель, 238 нче, 2016 ел, 27 декабрь, 1009 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында һәм гражданнарның кайбер категорияләрен торак урыннар белән тәэмин итү турында» 2010 ел, 8 декабрь, ФЗ-342 нче Федераль закон нигезендә торак урыннар белән тәэмин ителүче гражданнарга милеккә түләүсез яки социаль найм буенча торак урыннар бирү, аларга торак урын

сатып алу йә төзү өчен бер тапкыр акчалата түләү бирү кагыйдәләренә, 12 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«г) торак урынында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санын раслаучы белешмәләр;».

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2013 ел, 17 июнь, 414 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль законны нигезендә гражданнарны торак белән тәэмин итү максатларында төзелә торган торак-төзелеш кооперативлары әгъзаларына кабул ителергә хокуклы гражданнар исемлекләрен формалаштыру кагыйдәләренә, 4 пунктның «е» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«е) торак урынында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санын раслаучы белешмәләр;».

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль кулланылыштагы торак фондының торак урыннарын наемгага алу шартнамәләре буенча торак урыннар алуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2018 ел, 7 июнь, 432 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 04 апрель, 271 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Социаль кулланылыштагы торак фондының торак урыннарын наемгага алу шартнамәләре буенча торак урыннар алуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) торак урынында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санынраслый торган белешмәләр;»;

3 пунктчада «дәүләт теркәве органнары белешмәсе» сүзләрен «хокукларны теркәү органыннан мәгълүматлар» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин